# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ЙӨЗНЕҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА ТӨРКИ-ТАТАР ӘДӘБИ-МӘДӘНИ БАГЛАНЫШЛАРЫ

© Р.Г.Ханнанов

В статье раскрываются тюркско-татарские литературные взаимосвязи конца XIX – начала XX веков, выявляются условия формирования некоторых литературных жанров у тюркских народов.

Һәр милләтнең әдәбияты, нигездә, мөстәкыйль булуына карамастан, әйләнә-тирә иҗтимагый-тарихи чынбарлык белән тыгыз бәйләнештә яши, дөнья әдәби процессына барып тоташа, гомуми әдәби закончалыкларга буйсына. XIX гасыр ахыры – XX гасырның башында көнчыгыш классикасы контекстында үскән, камилләшкән һәм баеган татар әдәбияты өчен дә әлеге канун уртак.

Мәгълүм булганча, Шәрык дөньясы татар әдипләренең игътибарын һәрвакыт җәлеп итә. Шәрык илләрендә иранлылар, гарәпләр, таҗиклар, үзбәкләр, төрекләр, азәрбайҗанлылар, төркмәннәр, казакълар, кыргызлар, уйгурлар һәм башка халыклар яши. Әлеге төбәкләрдә гомер итүчеләрне, ягъни Шәрык халкын бер нәрсә берләштерә – ул ислам дине. "Ислам, кайбер башка диннәр кебек, рухи тормыш эшчәнлеген, идеологияне, мәдәниятне үз тәгълиматы белән шактый дәрәҗәдә яраклаштыра, шуның нәтиҗәсендә, этник, региональ, тарихи аерымлыкларга да карамастан, нигез төшенчәләр, моментлар туа (Аллаһының берлеге һәм кодрәтлелеге, Мөхәммәт пәйгамбәр – Аллаһының илчесе; тәмуг-җәннәт төшенчәләре һ.б.). Мөселман халыкларының, шул исәптән, төркиләрнең дә язма әдәбиятларында, ислам дине белән мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә, күп кенә уртак образлар, мотивлар киң таралыш таба" [1].

Ислам диненә бәйле шактый алга киткән фән һәм мәдәният тә төркиләрне бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тота. Төрки халыкларның бер вәкиле буларак, татарлар да үз кардәшләре белән аралашып һәм дустанә мөнәсәбәттә яши.

XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы – татар халкының милләт буларак формалашу, милли азатлык өчен көрәшнең тагын да көчәю, милли үзаң үсү чоры. Моңа билгеле дәрәҗәдә бу еллардагы инкыйлаблар да тәэсир ясады. Бу дәвердә алдынгы карашлы фикер ияләре, әдип-галимнәр милләтебезнең үткәне, бүгенгесе, киләчәге, аның дөнья халыклары арасында нинди урында торуы, бердәм әдәби тел булдыру, яшьләргә дөрес, заманча тәрбия бирү турында төптән уйлана башлыйлар. Бу хәл әдәбиятта да үзен сиздерә.

Дөньядагы кайсы гына халыкның әдәбияты формалашуын, үсеш эволюциясен алып карамыйк, без аның, иң беренче чиратта, милли традицияләргә нигезләнүенә игътибар итәрбез. Ләкин әдәбият, нинди генә бай тарихка ия булмасын, "башка халыкларның рухи-эстетик мирасы белән тыгыз мөнәсәбәткә керми яши алмый. Шуңа күрә безнең көннәрдә әдәбият һәм культура тарихын тар милли кысаларда гына өйрәнү һич мөмкин түгел. Димәк, әдәбият белеме фәнендә әдәбиятларның үзара йогынтысы һәм бәйләнеше мәсьәләләренә торган саен күбрәк әһәмият бирә бару – закончалыклы күренеш" [2]. Шуннан чыгып, татар әдәбиятының да, дөнья әдәбиятлары, әбигрәк тә тугандаш төрки халыклар әдәбиятлары белән тыгыз мөнәсәбәткә кереп, аларның прогрессив традицияләрен иҗади үзләштерү юлында ясаган гаять әһәмиятле адымнарын күздән кичерү актуаль бурыч булып тора. "XIX йөзнең икенче яртысыннан башлап әдәби бәйләнешләр гомумдөнья масштабын алды, һәм һәр аерым халыкның әдәбият факты шуның белән бергә дөнья әдәбияты факты булып әверелде" [3].

Әйе, татар матур әдәбияты күпгасырлар буе бары кулъязма рәвешендә генә үсә, шундый юл белән үз укучысын таба. Ләкин XVIII гасырдан басма әдәбият та зур тизлек белән халыкка тарала башлый. "Октябрьгә кадәрге чорда – якынча ике йөз ел эчендә – татар телендә барысы илле миллион тираж тәшкил иткән унбер мең китап чыга. Шуларның биш йөзе – татар әдипләренең әсәрләре" [4]. Бу – чоры өчен шактый югары күрсәткеч. Шул ук вакытта татар халкының мәгърифәтлелеген, югары культурага һәрдаим омтылып яшәвен дәлилли торган бер факт та. "Халыкның культурасы никадәр югары булса, аның башка милләтләр белән бәйләнешләре дә шулкадәр тыгыз була, ә үзара аралашып яшәү әлеге халыкның үз милли культурасын тагын да югарырак баскычка күтәрү мөмкинлеге бирә" [5].

XX гасыр башларында, тарихи шартларга бәйле рәвештә, башка төрки халыклар белән чагыштырганда, татар мәдәнияте шактый алга киткән була. Октябрь революциясенә кадәр һәм Совет хакимиятенең беренче елларында төрки телләрдә язылган китапларның, хезмәтләрнең зур

өлеше Казан шәһәрендә басылып чыгуы да моңа дәлил булып тора. XIX йөзнең азакларыннан башлап, Казан шәһәре төрки халыклар өчен белем-культура, революцион хәрәкәт үзәкләреннән берсе була.

Боларның барысы да әлеге чорда милли элитабыз, интеллигенция вәкилләре үсеп җитлегүенә, аларның дөньяда барган төрле вакыйгапроцессларга үз карашлары формалашуга, шулай ук революцион-демократик татар әдәбиятының барлыкка килүенә, зур тизлек белән үсеп китүенә сәбәп була. Озакламый татар әдәбияты царизм чорында үсә алмый калган яки бөтенләй югалу куркынычы янаган башка төрки халыкларның әдәбиятларына үрнәк булырлык прогрессив сыйфатларны мәйданга чыгара башлый.

"Татар әдәбияты, аның алдынгы шагыйрь һәм язучылары көнчыгыш әдәбиятларның язмышында шактый зур роль уйнадылар" [6]. Мәсәлән, "татар әдәбияты казакъ һәм Урта Азия халыкларының әдәбиятларында роман, повесть, драма кебек жанрларның формалашуына этәргеч булды", [7] "кырымлылар белән берлектә, төрек һәм рус әдәби багланышларын тәэмин итүдә билгеле бер роль уйнады (Муса Акъегетзадә, Гаяз Исхакый, Садрый Максудый һ.б.)" [8]. Ә "татарларны фарсы һәм гарәп әдәбиятлары белән таныштыруга үзбәк әдәбияты шактый өлеш кертте" [1].

Татарларның башка төрки халыкларга булган әдәби-мәдәни йогынтысы XIX гасырда үзен көчле сиздерә. Моңа күпмедер дәрәҗәдә халкыбызның Казахстан, Урта Азия якларына гаиләгаилә күчеп китүе дә, башка төрки милләт вәкилләре белән катнаш гаиләләр коруы да сәбәпче булып тора. Шул ук вакытта татар телендә басылган китапларның Шәрык дөньясының һәр төбәгенә таралган булуы, татар уку йортларында бик күп төрле төрки милләт вәкилләренең белем алуы да йогынты ясамый калмый. Үзенең бер чыгышында күренекле үзбәк шагыйре Гафур Голәм болай ди: "Минем яратып укыган китапларым ул вакытта Казанда, Оренбургта һәм Бакуда басыла иде. Бигрәк тә мин Казанда нәшер ителгәннәрне күп укый идем. Әле яшьлек елларымда ук Г.Тукай, М.Гафури, Г.Ибраһимов һәм башкаларның әсәрләре белән таныш идем. Казан минем өчен Кәгъбәдән югарырак дәрәҗәдә тора иде" [9]. Әлеге фикер татар әдәбиятының башка төрки халыкларның әдәбиятлары үсешенә ясаган йогынтыны тагын бер кат исбатлап куя.

Күргәнебезчә, төрки халыкларның бер-берсенә ясаган тәэсире үзен көчле сиздерә. Бер-берләре белән даими аралашу, рухи байлыклар алмашуда төркиләр өчен телләр белү әһәмиятле фактор булып тора. Ләкин бу – күпләр өчен зур авырлык тудыра торган мәсьәлә. Шуның нәтиҗәсендә, әдәбият өлкәсендә тәрҗемәчелек эшчәнлеге киң җәелә һәм төрки әдәбиятлар арасындагы багланышларны көчәйтүче төп ысулга әйләнә. Бүгенге көн сүзгә-сүз тәрҗемә әсәрләрдән аермалы буларак, XIX-XX йөзләрдә иркле тәрҗемә киң җәелгән була. Шуңа күрә әсәрләрнең чыганак телдә яңгыраган фикерләре, идеяләре, проблематикасы берникадәр үзгәреш кичерә. Бу исә, үз чиратында, бер төрки мәмләкәттә иҗат ителгән әсәрләр башка төрки халыкларның үз милли хәзинәләренә әверелүгә яки икенче вариантын табуга китерә. "Элек, бигрәк тә милли әдәбиятларның формалашу чорында, тәрҗемә әсәрләрнең вазифасы зур була. Алар, милли әдәбиятның органик өлешен тәшкил итеп, әлеге халыкның үз телендә иҗат ителгән әсәрләрдән бер дә аерылмыйлар" [10]. Чөнки тәрҗемә әсәре халыкның теленә, милли закончалыкларына, тәрбияви бурычларны үз эченә алган потенциалына яраклашырга мәҗбүр һәм тиеш. Шуңа да төрле халыклар арасында аерым бер әсәр (мәсәлән, төрек драматургы Нәмыкъ Кәмалның "Зәваллы чоҗык" пьесасы азәрбайҗан һәм татар телләренә тәрҗемә ителгән) төрле-төрле вариантларда яшәргә мөмкин. Шунысы мөһим: тәрҗемә ителәсе әсәр халыкның рухи ихтыяҗларына бәйле рәвештә сайлап алына.

Күргәнебезчә, иркле тәрҗемә эшчәнлегенең милли әдәбиятлар формалашкан чорда, ягъни XIX гасыр – XX гасыр башларында әһәмияте гаять зур була. Ул кайбер төрки халыкларда моңа кадәр булмаган яңа жанрлар (мәсәлән, татарларда драматургия жанры төрек әдәбияты йогынтысында барлыкка килә, казакъ халкының милли прозасы татар әдәбиятына бәйле рәвештә туа һ.б.), әдәби агымнар, иҗат методлары, тел-сурәтләү чаралары формалашуга китерә.

Ләкин, кызганычка каршы, Октябрь инкыйлабыннан соң татарларның Шәрык дөньясы белән багланышлары әкренләп сүрелә башлый. Татар уку йортларының күбесендә гарәп, фарсы, төрек телләре өйрәнелүдән туктый. Милләтчелеккә, дини хорафатларга өндәүче дигән шигарь астында бик күп кыйммәтле әдәби һәм фәнни хезмәтләребез яндырыла. XX гасырның утызынчы елларында татарларның меңәр ел буе кулланган гарәп әлифбасы мәҗбүри рәвештә башта латин графикасына, ә аннары кириллицага алыштырыла. Болар барысы да татар халкының Шәрык белән күп гасырлар буе дәвам иткән багланышларын юкка чыгара. Әлеге сәясәт патша Россиясе елларында ук башлангыч алган була. Ул төрки халыкларның яңарыш хәрәкәтенә даими аяк чала. Инде халкыбыз азатлык өчен көрәш буларак кабул иткән инкыйлаблар башлангач та төркиләргә үз илләрендә мөстәкыйль рәвештә яшәү

насыйп булмый. "Татарның башкорт белән, башкортның казакъ белән якынаюы кебек берләшүләр большевиклар хакимиятенә бөтенләй ошамый" [11], аларны һәрвакыт куркыта килә.

Татар демократик интеллигенциясенең Казанда милли театр оештырып җибәрү турындагы гозерен дә Россия түрәләре кат-кат кире кага киләләр. Ләкин татар мәгърифәтчеләренең театр эшен оештыруга омтылышы шактый ук көчле булып чыга.

Татар әдәбиятында, инде алдарак искәртелгәнчә, яңа жанр, әдәби юнәлешләр формалашып китүдә бигрәк тә төрек әдәбияты алыштыргысыз роль уйный. Шуның йогынтысында үсеш алган татар мәгърифәтчелек хәрәкәте гасырлар буе формалашкан эстетик кыйммәтләрне җимерә, алар урынына яңалары барлыкка килүне таләп итә. Әлеге иҗат методына корылган әсәрләрдә хатын-кызның ир-атлар белән бертигез хокукларга ия булырга тиешлеге, заманча белем һәм тәрбия бирү, халыкны наданлыктан коткарачак фән һәм мәдәният тудыру кебек идеяләр өстенлек ала. Болар барысы да 1861 елгы реформадан соң үсәргә омтылган татар мәгърифәтчелек әдәбиятын да канәгатьләндерә, чөнки аның формалашуы да, мәсәлән, төрек әдәбиятындагы үзгәрешләр чоры кебек үк, консерватив феодал карашларга каршы юнәлтелгән көрәш шартларында бара.

Нәкъ шушы үзгәрешләр, төрле иҗтимагый-мәдәни, әдәби каршылыклар дәверендә татар әдәбиятының әле моңарчы тарихында булмаган жанр – драматургия формалаша. Язма татар әдәбиятының күпгасырлык тарихы булса да, моңа кадәр әле әдипләребез тарафыннан сәхнә әсәрләре иҗат ителми. Тәүге татар пьесалары XIX гасырның соңгы чирегендә күренә башлый. Әлбәттә, бу, беренче чиратта, татар халкының үз милли театры булмау белән дә аңлатыла. Моның шулай икәнлегенә Галиәсгар Камал иҗатын гына мисал итеп китерү дә җитә. Ул "Бәхетсез егет", "Өч бәдбәхет", "Кызганыч бала" (төрек язучысы Нәмык Кямалның "Зәваллы чоҗык" драмасының тәрҗемәсе) исемле әсәрләрен иҗат иткәннән соң, әлеге жанрда алты-җиде ел буе бернәрсә дә язмый. 1906 елда үзенең яңадан драматургия өлкәсендә эшли башлавын ул болайрак аңлата: "Шулай маташа торгач, 1905 ел килеп җитә. Шәһәрнең "азган-тузган" яшьләре театр артындагы урамда, приказчиклар клубында спектакль куялар. Менә шуннан соң миндә ничә ел томаланып яткан дәрт яңадан кузгала. <…> Театр куюлар көчәя, ләкин пьесалар юк. Шуннан электә язылган кыска "Бәхетсез егетне" киңәйтеп, сәхнәгә куярга яраклы хәлгә китерәм. <…> Халык һаман яңадан-яңа пьесалар сорый. "Уйнашны"да язып карыйм, "Дәҗҗал" да языла, башкалары да. Кариев һаман да туймый" [12]. Әйтергә кирәк, Г.Камалны 1905 ел революциясе тәэсирендә татар театрының оешып китүе рухландыра, иҗатка этәрә.

Күргәнебезчә, драматургия ныклап аякка бассын өчен, аңа үз сәхнәсен, үз артистларын һәм үз тамашачысын табу кирәк була. "Бары тик сәхнә генә драматургның әйтергә теләгән фикерен һәм үзалдына максат итеп куйган тәрбияви йогынтысын тамашачыга җиткерә ала" [13], – дип билгеләп үтә рус драматургы А.Н.Островский.

Алдарак аталган шарт, ниһаять, тормышка аша. Моңа "Шимбә" түгәрәгенең этәргече зур була. 1903 ел ахыры – 1904 ел башларында рус мәктәпләрендә укучы татар яшьләре, шимбә көннәрендә җыелып, әдәбият кичәләре үткәрүне гадәткә кертәләр. Шуңа аларны "шимбәчеләр" дип йөртәләр. "Шимбә" түгәрәгенең әгъзәлары 39 кешегә җитә" [14]. Түгәрәк җыелышларында, рус һәм Көнчыгыш классикларының иҗатлары белән бергә, яңа татар әдәбияты әсәрләрен укып өйрәнүгә дә зур игътибар бирелә [15]. Бер үк вакытта татар телендә спектакль уйнау мәсьәләсе дә көн тәртибенә куела. "Шимбәче"ләр 1904 елның 18 гыйнварында Казанның Беренче тау урамындагы Габитовлар фатирында түгәрәкнең беренче спектакльләре – төрек драматургы Н.Кямалның "Зәваллы чоҗык" драмасының ирекле тәрҗемәсе буларак Г.Камал тарафыннан иҗат ителгән "Кызганыч бала"ны һәм "Гыйшык бәласе" (авторы билгесез) комедиясен сәхнәләштерәләр. "Бу факт Тифлиста чыга торган "Шәркый рус" газетасына барып җитә һәм әлеге вакыйганы хуплаган мәкалә басыла" [14].

Билгеле, татар җәмәгатьчелеге арасында милли театр оештырып җибәрү теләге белән йөрүчеләр бер "Шимбә" түгәрәге яшьләре генә булмый. Татар театрын, рәсмиләштереп, киң мәйданга чыгарырга омтылучылар артканнан-арта, көчәйгәннән-көчәя бара. Гәрчә зур уңыш белән тәмамланмасалар да, 1905 ел инкыйлабы алдыннан төрки-татар дөньясында спектакльләр бик күп тапкырлар куела килә. Мәсәлән, 1903 елның 30 декабрендә Казанның "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе шәкертләре тарафыннан Г.Камалның "Бәхетсез егет", ә 1904 елның язында Екатерининская (хәзерге Г.Тукай урамы) урамындагы Русча-татарча кызлар мәктәбе бинасында Г.Ильясиның "Бичара кыз" әсәрләре сәхнәләштерелә (әлеге спектакльләрдә катнашучыларның күбесе киләчәктә "Шимбә" түгәрәге әгъзалары булып китә дә инде). Соңгысына кырыклап кеше чакырылып, ул татар театрын рәсмилеккә шактый якынайткан бер факт булып тора. 1904 елның 4 апрелендә исә Ташкентта подполковник Сәхиб Еникеев фатирында, байтак

тамашачы җыеп, "Гыйшык бәласе" спектакле уйнала. Шулай ук 1905 елда Уфаның "Госмания" мәдрәсәсендә шәкертләр тарафыннан берничә драма әсәре сәхнәләштерелүе мәгълүм.

Ниһаять, татар театры тарихында зур сәхнәгә чыгарылган беренче рәсми спектакль Уфаның алдынгы интеллигенциясе, укымышлы яшьләре катнашында 1906 елның 21 апрелендә Приказчиклар клубында була. Ул – Г.Исхакыйның шул чорда иң популяр әсәрләреннән берсе "Өч хатын белән тормыш" драмасы. Ә Казанда исә тәүге рәсми ачык спектакльләр әлеге елның 5 маенда шулай ук Приказчиклар клубында (Зур Кызыл урам, 29 йорт) куела. Биредә ике пьеса – Г.Камалның тәрҗемә әсәре "Кызганыч бала" драмасы һәм билгесез авторның "Гыйшык бәласе" комедиясе уйнала.

Әмма рәсми рәвештә беренче ачык татар спектакле уйналуы 1906 елның 22 декабрендә Казанда булды дип кабул ителә (чагыштыру өчен: азәрбайҗан халкының театр тарихы исә 1873 елдан ук башлана). Чөнки губернатор тарафыннан татарча спектакль куюны хуплаган рәсми кәгазь әлегәчә бирелмәгән була. Һәм менә "рөхсәт итәм" дигән виза алынгач, ике йөздән артык тамашачыны үзенә сыйдырган Яңа клуб сәхнәсендә 22 декабрь көнне Г.Камалның "Кызганыч бала" драмасы уйнала. Спектакль һәр җәһәттән көчле яңгыраш ала. Татар театрының чын-чынлап зур мәйданга чыгуы турында фикерләр байтак була. Әле бик күп милләтләренең драматургия һәм сәхнә сәнгате формалашуына, үсешенә нигез булачак әлеге әһәмиятле факт төрки дөнья өчен олы вакыйгага әйләнә, вакытлы матбугатта күләмле мәкаләләр басыла. Аларда татар театрының Көнчыгыш һәм Көнбатыш традицияләрен дәвам иттергән хәлдә мәйданга килүенә басым ясала.

Яңа туган милли театрга җәмәгатьчелек һәртөрле ярдәм күрсәтергә омтыла. Әлбәттә, беренче нәүбәттә аны пьесалар белән тәэмин итү кирәк була. Ләкин ныклап тотынып, драма әсәрләре иҗат итү өчен, авторларыбызның тәҗрибәсе җитенкерәми. Шул һәм башка сәбәпләр аркасында XX гасыр башында татар әдәбиятының төрки әдәбиятлар белән бәйләнешы тагын да тирәнәя. Бу очракта төрек әдәбиятына мөрәҗәгать итү, аның тәҗрибәсен үзләштерү алгы планга чыга.

Шуңа күрә татар сәхнә әдәбияты формалашуны, аның үсеш үзенчәлекләрен күзәтәбез икән, төрек әдәбияты белән тыгыз бәйләнешләргә игътибар итми калу мөмкин түгел. "Татар драматургиясе һәм театр сәнгате үсеп китүдә этәргечне шактый дәрәҗәдә төрек авторлары ясый" [11].

Тугандаш халыклардан булган төрек әдәбиятында да хакимлек иткән идея-эстетик үзенчәлекләргә бәйле рәвештә, тәүге сәхнә әсәрләребез заман проблемалары белән тыгыз үрелеп формалаша, патша самодержавиесенең колониаль сәясәтенә, кысуларына карамастан, кыю, халыкчан фикерләрне таратуга басым ясый. Шул рәвешле, төрки халыклар белән тыгыз бәйләнештә татар сәхнә әдәбияты һәм сәнгате тизләтелгән үсеш юлы белән бара, киң массаны аң-белемле итү, мәгърифәт тарату, укучы-тамашачыны тәрбияләү, мәдәниятле итү кебек мәсьәләләрне үзенә бурыч итеп куя.

Күргәнебезчә, XIX гасыр ахыры – XX йөзнең беренче яртысында төрки-татар әдәби бәйләнешләры үзен шактый көчле сиздерә. Төрки әдәбиятлар бер-берсе белән тыгыз элемтәдә үсә, камилләшә һәм байый. Моның башлангычы төрки милләтләрнең дин берлегенә, Россиянең кырыс сәясәтенә буйсынып яшәргә мәҗбүр ителүгә, төрле кадими карашларга нигезләнеп белем, тәрбия бирүгә, шуңа бәйле аң-белем үсешенә омтылыш һәм мәгърифәтчелек хәрәкәте киң җәелүгә барып тоташа. Төрки әдәбиятларда уртак мотивлар, идея-эстетик үзенчәлекләр барлыкка килә. Бу, үз чиратында, аерым халыкларда әле моңа кадәр булмаган әдәби жанрлар, метод-алымнар, төрле әдәби хәрәкәтләр формалашуга китерә. Бигрәк тә XIX гасыр ахыры – XX йөзнең беренче яртысында төрек һәм татар, татар һәм казакъ, татар һәм азәрбайҗан әдәбиятлары бер-берсенең үсешенә, камилләшү һәм баюына көчле тәэсир ясаганнар. Татар һәм төрек әдәбиятлары нигезендә казакъ милли әдәбиятында проза жанры барлыкка килсә, төрек, азәрбайҗан халыкларының сәхнә әдәбияты һәм сәнгатенә бәйле рәвештә, татар милли драматургиясе һәм театры үзенең беренче адымнарын ясый, зур тизлек белән үсеп китә, татар әдипләренең әсәрләре төрки дөньяда киң таралыш таба, тәрҗемәчелек, бигрәк тә ирекле тәрҗемә эшчәнлеге актуальләшә.

Төрки халыкларның уртак тамырлары борынгы дәверләргә барып тоташа. Тугандаш халыклар белән татар халкы арасындагы әдәби-мәдәни бәйләнешләрне өйрәнү дә төрле кызыклы ачышларга китерә, безнең әһәмиятле бурычыбыз булып тора. Ул әлеге гомуми үсештә татар эстетик фикеренең урынын ачыклау мөмкинлеген дә бирә.

* * * * * * * * * *

1. Миңнегулов Хатыйп. Татар-төрек әдәби бәйләнешләры // Татарстан. 1993. №9.
2. Ганиева Р. Әдәби бәйләнешләр: Көнбатыштан үрнәк алып // Татар әдәбияты тарихы. XX йөз татар әдәбияты. 6 томда: 3 том. Казан, 1986.
3. Конрад Н.И. К вопросу о литературных связях // Сб.: Интернациональное и национальное в литературах Востока. М., 1972.
4. Кәримуллин Ә.Г. Китап – халык хәтере // Социалистик Татарстан, 1984.

5. Дима Александр. Принципы сравнительного литературоведения: Перевод с румынского. М., 1977.
6. Юсуф Хос Ходжиб. Кутадгу билиг. Ташкент, 1971.
7. Казахская литература и ее интернациональные связи. Алма-Ата, 1978.
8. Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики). Казань, 1993.
9. Голям Гафур. Писатель, революционер, ученый. // Материалы научной конференции, посвященной 90-летию Галимджана Ибрагимова. Казань, 1980.
10. Лихачев Д.С. Развитие русской литературы X-XVII веков. Эпохи и стили. Л., 1973.
11. Галимуллин Фоат. Табигыйлеккә хилафлык. Казан, 2004.
12. Совет әдәбияты. 1933, №1.
13. Островский А.Н. Полн.собр.соч.: В 12 т. М., 1978. Т.10.
14. Мәхмүтов Һ., Илялова И., Гыйззәт Б. Октябрьгә кадәрге татар театры. Казан, 1988.
15. Байчура Ш. Татар яшьләре хәрәкәте һәм Фатих Әмирхан // Казан утлары, 1966. №1.

# THE TURKIC-TATAR LITERARY INTERCOMMUNICATIONS OF THE END OF XIX – THE BEGINNING OF XX CENTURIES: LITERARY-CULTURAL CONDITIONS

**R.G.Hannanov**

This article is about the Turkic-Tatar literary intercommunications of the end of XIX – the beginning of XX centuries, the conditions of forming of some literary genres of Turkic nations.